**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2476**
**19.04.2024**

Башкарма комитетның 2023 елның 14 июнендәге 5100 номерлы Карары белән расланган капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында белдерү кәгазе һәм капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары (закон актлары нигезләмәләре) үз көчен югалтуны тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 14 июнендәге 5100 номерлы Карары белән расланган капиталь төзелеш объектын сүтүне планлаштыру турында белдерү кәгазе һәм капиталь төзелеш объектын сүтүне тәмамлау турында белдерү кәгазе җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.6.1 пунктының 4 пунктчасына, «социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н. Лашинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов